# Шәүкәт Галиев шигырьләрен рус мәктәбенең татар төркемнәрендә өйрәнү. 5 – 11 нче сыйныфлар.

# Мәктәп программасында Шәүкәт Галиев иҗаты

**5 НЧЕ СЫЙНЫФ: ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ. "АЛТЫН КУЛЛАР", "ХӘЗИНӘ", "ТЕЛЛӘР БЕЛҮЧЕ КАЛӘМ","МАГНИТОФОН ОНЫТМЫЙ", "САУМЫСЕЗ, АРЫШЛАРЫМ!" 3 СӘГ.**

**ЯТЛАУ ӨЧЕН: "ХӘЗИНӘ", "МАГНИТОФОН ОНЫТМЫЙ" ШИГЫРЬЛӘРЕ ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ.**

**6 НЧЫ СЫЙНЫФ:ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ "САУМЫСЕЗ, АРЫШЛАРЫМ!" 1 СӘГ.**

**8 НЧЕ СЫЙНЫФ: ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ. ИҖАТЫ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ. "ӘТКӘЙГӘ ХАТ".2 СӘГ.**

**ЯТЛАУ ӨЧЕН, "ӘТКӘЙГӘ ХАТ" (ӨЗЕК) ТӘКЪДИМ ИТЕЛӘ.**

**11 НЧЕ СЫЙНЫФ: БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ. ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ ИҖАТЫ. "УРМАН КҮЧӘ УРАМГА", "БАГАНА". 2 СӘГ.**

# Төркемләү:

1. Традицион метод белән укыту.
2. Иҗади үсеш технологиясе.
3. Яңа педагогик технологияләр кулланып укыту.

# 1 нче дәрес. Ш. Галиевнең биографиясе. “Алтын куллар” шигыре.

1.“Алтын куллар” шигыре өстендә эш:

- строфадан - строфага анализ бирү, сурәтләү чараларын билгеләү;
- шигырь төзелешенә хас үзенчәлекләр: кыска дүртьюллыклар, халык әдәбиятында кебек авазлаш рифмалар.

2. Нәтиҗә чыгару: безнең бәхетебез – безнең кулларда.

# Иҗади үсеш технологиясе

**5 нче сыйныфта Шәүкәт Галиевнең “Хәзинә” шигырен өйрәнү.**

# Дәрес максаты:

**Китапханәләр тарихы белән таныштыру, шигырьне дөрес итеп, аңлап укуларына ирешү, дөрес уку күнекмәләрен камилләштерү, китап укуга кызыксыну тәрбияләү.**

# Уку максатын кую:

**Төркемнәрдә тикшерегез:**

**Китапханәләр нигә кирәк?**

**Китап нәрсә ул?**

**Кеше ни өчен китап укырга тиеш?**

**Син китап җыяр идеңме, әллә алтын – көмешме?**

# Үз – үзеңә бәя кую.

**Дәрестә башкарылган һәр күнекмәне үтәгәннән соң бәя куела.**

# Китап уку — иң яхшы белем алу.

# Уку мәсьәләсен чишү.

**1. Төркемнәрдә тикшерегез:**

**- “Хәзинә” шигырен уку.**

**- Сез бу сүзләрне ничек аңлыйсыз: *хәзинә, бакканнар, мөгаен, борын – борыннан?***

***хәзинә - байлык, богатство, бакканнар – караганнар, мөгаен – наверное, борын – борыннан – давным – давно.***

## Сораулар:

- Хәзинәне ничек эзләгәннәр?

- Хәзинә нәрсә ул?

- Китапханәдә нинди хәзинә бар?

**Үз – үзенә бәя кую.**

# Түбәндәге мәкальләрнең мәгънәсен ачыклагыз:

**Китап – белем чишмәсе.**

**Китап – тормыш көзгесе.**

**Китапсыз йорт – кошсыз урман.**

**Алтын җирдән табыла, акыл – китаптан.**

**Үз – үзеңә бәя кую.**

**- Китап – якын дус, диләр. Моны ничек аңлыйсыз?**

**- Китапның дошман булуы мөмкинме?**

**Үз – үзеңә бәя кую.**

Әгәр китап сөйләшә белсә, ул үзенең укучыларыннан нинди кагыйдәләрне үтәүне катгый таләп итәр иде икән? Дәфтәрләрегезгә языгыз.

# Кагыйдәләр үрнәге:

-Зинһар өчен, пычрак кул белән тотынмагыз:

башка китап укучылар мине кулларына алсалар, миңа оят булачак.

-Мине ручка белән сызгаламагыз – бу килешми.

-Битләремне бөкләмәгез.

-

# Рефлексия.

- Бүген дәрестә без нинди шигырь укыдык?

- Шагыйрь китапханәне ни өчен хәзинә дип атый?

- Китапны ничек сакларга кирәк?

Үз – үзеңә бәя кую.

# 3 нче дәрес. “Саумысез, арышларым!”. Методик киңәшләр.

1. **Өлешләргә бүлү: лирик геройның туган ягын сагынып кайтуы, юксынуы һәм икмәкнең кадерен белү.**
2. **Хиснең сәбәбен билгеләү.**
3. **Строфадан - строфага хиснең үзгәрүен, тулылануын күзәтү.**
4. **Шигырьнең темасын билгеләү: туган җирдән аерылган лирик геройның сагыну хисләре.**

# “Туган телем – иркә гөлем”.
## Әдәби – музыкаль кичә.

... Күрсәң иде малайның

Ничек гаҗәпләнгәнен:

-Кара әле, яшь чакта

Мин татарча белгәнмен?!

“Магнитофон онытмый...”

# “Әткәйгә хат” поэмасы. 8 нче сыйныф. (2 сәг.)

**Максат: анализ аша әсәрдә шагыйрь тормышын, хис – омтылышларының изгелеген, әсәрне тәэсирле иткән сәнгатьчә алымнарны танып белү.**

**1. Солдат хатларын күрсәтү.**
**2. Ш. Галиевнең әтисенең хатларыннан өзекләр уку.**
**3. “Минем беренче гомерем” – автобиографик әсәр. Өзекләр уку.**
**4. Поэманы уку.**
**5. Текстуаль план төзү, эчтәлек сөйләү.**
**6. Лирик геройга характеристика.**
- **лирик геройны характерлый торган юлларны уку;**
- **әтисе турында сөйләшү;**
- **лирик герой өчен хас сыйфатлар.**

**7. Әңгәмә.**
**8. Сурәтләү чараларын билгеләү.**
**9. Ни өчен поэма” Әткәйгә хат” дип атала?**

# Балалар шагыйре Шәүкәт Галиев иҗаты. 11 нче сыйныф.

1. Төркемнәргә бүленү.
2. Төркемнәр чыгышы: А) Балалар әдәбияты, төрләре. Ә) Балалар шагыйрьләре һәм шигырьләре.
3. Биремнәр: а) "Урман күчә урамга" шигырен анализлау, автор әйтергә теләгән фикерне ачыклау. ә) "Багана" шигырен анализлау, сынландырулар нинди максаттан кулланылуын ачыклау.
4. Шигырьләргә анализ:

- шигырь нәрсә турында?
- сурәтләү чаралары, әһәмияте;
- шигырьләрнең уртак якларын билгеләү;
- балалар язучысы буларак, Шәүкәт Галиев иҗатының үзенчәлеге нәрсәдә?

# 11 нче сыйныф өчен Шәүкәт Галиев иҗаты буенча тест биремнәре.

**1**. Шәүкәт Галиев кайда туган?

А) Арча районы Кушлавыч авылы.

Ә) Апас районы Олы Бакырчы.

Б) Минзәлә районы Югары Тәкермән авылы.

2. Шәүкәт Галиев кайчан туган?

А) 1906 нчы елның 15 нче февралендә.

Ә) 1938 нче елның 9 нчы февралендә.

Б) 1928 нче елның 20 нче ноябрендә.

3. Шәүкәт Галиев кайчан Казанга килә?

А) 1938 нче елда.

Ә) 1954 нче елда.

Б) 1953 нче елда.

4. Шәүкәт Галиев Мәскәүдә нинди курсларда укый?

А) Политик курсларда.

Ә) Шигырь язу курсларында.

Б) Әдәби курсларда.

5. Беренче китабы ничек атала?

А) Яңа көйләр".

Ә) "Шәвәли".

Б) "Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр".

6. 1962 нче елда нинди җыентыгы басыла?

А) Уйларым, серләрем".

Ә) "Камырша".

Б) "Тамчылар тамар чаклар".

7. 1972 нче елда нинди бүләк бирелә?

А) Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе.

Ә) Муса Җәлил исемендәге премия.

Б) Татарстан Республикасының халык шагыйре.

8. Г.Х. Андерсен исемендәгеПочетлы диплом нинди китап өчен бирелә?

А) "Заяц на зарядке" китабыөчен.

Ә) "Кызык" китабы өчен.

Б) "Тәмле йорт" китабы өчен.

9.Шәүкәт Галиев сүзләренә язылган җыр?

А) "Утыр әле яннарыма".

Ә) "Ялгыз аккош".

Б) "Әнкәй".

10. Бу юллар нинди шигырьдән:

Башкаларның “4”, “5” ле,

Ә ул тагын “2” ле алган.

А) “Онытылган”.

Ә) “Хәзинә”.

Б) “Шәвәли”.

11. Шигырьләренең төп герое кем?

А) Тимерша.

Ә) Закир.

Б) Шәвәли.

12. Бу юлларны кем әйткән: “Балалар әдәбиятында Тукайдан соң, Бари Рәхмәтләрдән соң туган бушлык бетте”.

А) Роберт Миңнуллин.

Ә) Хәсән Туфан.

Б) Сибгат Хәким.

# Хәсән Туфан:

**“Шәүкәт балалар әдәбияты төбәгенә… чын шагыйрь хәлендә килеп керде… һәм нәниләрнең, Тукайча әйткәндә, «фәрештә валчыклары»- нык, ак, пакъ, саф күңелләренә җан азыклары өләшү эшенә кереште. Аның бу иҗатта төп материалы – туган тел, Тукай әйткән матур тел”.**